# КАРАР
# Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Уразлы авыл җирлеге Кече Карамалы авылында гражданнарга үзара салым кертү турында

21 нче ноябрь 2022 ел № 3

"Россия Федерациясендә җирле узидарә оештыруның гомуми принциплары турында" 2003 елның 6 октябрендәге 121-ФЗ номерлы Федераль законнын 25,1, 56 статьялары, "Татарстан Республикасында җирле узидарә турында" 2004 елнын 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының Кече Карамал авылында гражданнар җыены **карар итте** :

1. 2023 елда Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының Уразлы авыл җирлеге территориясе, Кече Карамалы авылында яшәү урыны буенча теркәлгән, ташламалы категорияләрдән тыш (беренче төркем инвалидлар,көндезге формада укучы студентлар), Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының Уразлы авыл җирлеге территориясендә яшәүче, җирлек территориясендә тавыш бирергә хокукы булган, яшәү урыны буенча турыдан-туры теркәлгән, һәр балигъ булган кешедән 500 сум күләмендә үзара салым кертергә.

2. Алынган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә түбәндәгеләрне үтәү буенча юнәлтергә:

* авыл эчендәге юлларны ремонтлау (сатып алу, ташу, вак таш салу, килешү буенча эшләр өчен түләү) һәм Тукай урамындагы күперне ремонтлау (төзелеш материаллары (торбалар һ.б.) сатып алу, килешү буенча түләү);

* җәйге чорда территорияне чабу(ягулык-майлау материаллары сатып алу, килешү буенча эшләр һәм хезмәт күрсәтүләр өчен түләү);

* Кече Карамалы авылында юлларны тигезләү, кардан чистарту (ягулык-майлау материаллары, трактор өчен запас частьләр сатып алу, килешү буенча эшләр һәм хезмәтләр өчен түләү).

3. Гражданнар җыены нәтиҗәләрен түбәндәге адреслар буенча урнашкан мәгълүмат стендларында игълан итәргә:

- Татарстан Республикасы, Кама Тамагы районы, Кече Карамалы авылы, Кече урамы,1 нче йорт, авыл клубы бинасы; шулай ук Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының рәсми сайтында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә кабул ителгәннән соң 10 көн эчендә урнаштырырга.

Халык җыенында рәислек итүче ,
Татарстан Республикасы Кама
Тамагы муниципаль районы
Уразлы  авыл җирлеге башлыгы: М.Г.Хәмидуллин